КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 21 сентябрь г.Казань № 848

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы мәсьәләләре» 2019 ел, 1 ноябрь, 997 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 17 февраль, 116 нчы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Министрлык түбәндәге төп функцияләрне гамәлгә ашыру өчен җавап бирә:

3.1.1. Цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*), шул исәптән:

3.1.2. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын үстерү белән идарә итү (дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итүдән башка) (01.15.02*);

---

*Код билгеләнеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторы буенча.

3.1.3. Татарстан Республикасының ведомство дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү (01.15.01.2*);

3.1.4. Элемтә белән идарә итү (03.04*).»;

3.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Министрлык түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

3.2.1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

3.2.2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05*);

3.2.3. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

3.2.4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурслары белән идарә итү (01.07*);

пространство мәгълүматлары белән идарә итү (01.07.01*);

3.2.5. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

3.2.6. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.01*);

3.2.7. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*);

3.2.8. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән социаль-икътисадый мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат ресурсларын формалаштыру белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.01.1*);

3.2.9. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы белән дәүләти-хосусый партнерлык һәм хосусый инвестицияләр, инвестиция проектларын тормышка ашыруны комплекслы алып бару өлкәсендә инвестиция эшчәнлеген үстерү белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.10*);

3.2.10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе белән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу эшчәнлеге белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.08*);

3.2.11. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы белән матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.10*).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин